**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

# Об отмене ограничительных мероприятий (карантина), установленных на отдельной территории Теньковского сельского поселения муниципального образования «Камско-Устьинский муниципальный район Республики Татарстан» в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных

В связи с истечением 60 календарных дней после уничтожения последнего трупа больного восприимчивого животного и проведением противоэпизоотических и профилактических мероприятий, в соответствии со статьей $3^1$ Закона Российской Федерации от 14 мая 1993 года № 4979-I «О ветеринарии» **постановляю:**

1. Отменить ограничительные мероприятия (карантин), установленные в связи с неблагополучием по заболеванию бешенством животных на территории личного подсобного хозяйства по улице Ленина, дом 80, села Теньки в Теньковском сельском поселении муниципального образования «Камско-Устьинский муниципальный район Республики Татарстан» и территории радиусом 2 км от границ эпизоотического очага в Теньковском сельском поселении муниципального образования «Камско-Устьинский муниципальный район Республики Татарстан».

2. Признать утратившим силу Указ Раиса Республики Татарстан от 27 мая 2025 года № 412 «Об установлении ограничительных мероприятий (карантина) на отдельной территории Теньковского сельского поселения муниципального образования «Камско-Устьинский муниципальный район Республики Татарстан» в связи с ее неблагополучием по заболеванию бешенством животных».

3. Настоящий Указ вступает в силу со дня его подписания.

**Раис**
**Республики Татарстан** — **Р.Н. Минниханов**

АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казань, Кремль
04 августа 2025 года
№ 604

**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Тәмте авыл җирлеге аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Тәмте авыл җирлегендәге Тәмте авылының Ленин урамындагы 80 нче йортның шәхси ярдәмче хуҗалыгы территориясендә һәм «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Тәмте авыл җирлегендәге эпизоотия чыганагы чикләреннән 2 км радиустагы территориядә хайваннар котыру авырулы булганга, аларның имин булмавы сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Рәисенең «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Тәмте авыл җирлеге аерым территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның имин булмавы сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2025 елның 27 маендагы 412 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2025 ел, 04 август
№ 604